ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МЕНЗЕЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНЗӘЛӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

21.09.2026 г.Мензелинск № 319

**Махсус хәрби операциядә катнашучы (катнашкан) затларга һәм башка төркемдәге затларга ярдәм чараларын билгеләү турында**

Россия Федерациясе Президентының 2026 елның 15 маендагы «Махсус хәрби операциядә катнашучы (катнашкан) затларга һәм Россия Федерациясе субъектларындагы башка төркемдәге затларга гомуми бердәм база ярдәм чаралары турында» №327 Боерыгын гамәлгә ашыру максатларында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2026 елның 10 июлендәге «Махсус хәрби операциядә катнашучы (катнашкан) затларга һәм башка төркемдәге затларга ярдәм чараларын билгеләү турында» № 862 Карарына туры китереп,

КАРАР ЧЫГАРА:

1. Махсус хәрби операциядә катнашучы (катнашкан) затларга һәм Татарстан Республикасында яшәүче башка төркемдәге затларга түбәндәге ярдәм чараларын билгеләргә:

әлеге карарның 2 нче пунктында күрсәтелгән затларга, мәдәният, физик культура һәм спорт өлкәсендә эшчәнлек алып баручы Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының муниципаль учреждениеләренә, шулай ук җирле үзидарә органнары тарафыннан оештырылган күргәзмәләр, физик культура һәм спорт чараларына керү;

3 нче пунктның «б» һәм «е» a пунктчаларында күрсәтелгән затларны мәҗбүри тәртиптә (шул исәптән бер мәгариф учреждениесеннән икенчесенә күчергәндә) аларның гаиләләре яшәгән җиргә иң якын урнашкан муниципаль мәгариф учреждениеләренә: мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программалары буенча мәгариф эшчәнлеге алып баручы муниципаль мәгариф учреждениеләренә, шул исәптән, озынайтылган көн төркемнәренә кертү;

әлеге карарның 2 нче пунктында күрсәтелгән затларны, аларның 3нче

пунктның «б» һәм «е» а пунктчаларында аталган затларын муниципаль мәгариф учреждениеләрендә, мәктәпкәчә белем бирү программалары буенча мәгариф эшчәнлеге алып баручы учреждениеләрдә карау һәм тәрбияләү өчен ата-аналардан (законлы вәкилләреннән) алына торган түләүдән бөтенләй азат итү;

агымдагы карарның 2 нче пунктында күрсәтелгән затларны, аларның 3нче пунктының «б» һәм «е» а пунктчаларында аталган затларны муниципаль мәгариф учреждениеләрендә, башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программалары буенча мәгариф эшчәнлеге алып баручы учреждениеләрдә, озынайтылган көн төркемнәрендә карау һәм тәрбияләү өчен ата-аналардан (законлы вәкилләреннән) алына торган түләүдән бөтенләй азат итү;

әлеге карарның 3 нче пунктының «б» һәм «е» а пунктчаларында күрсәтелгән затларга, муниципаль мәгариф учреждениеләрендә, башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программалары буенча мәгариф эшчәнлеге алып баручы учреждениеләрдә, өстәмә гомуми белем бирү программалары буенча; өстәмә гомуми белем бирү программалары буенча гамәлгә ашырыла торган дәресләргә бушлай керү;

әлеге карарның 3 нче пунктының «б» һәм «е» а пунктчаларында күрсәтелгән затларны, муниципаль мәгариф учреждениеләрендә, башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программалары буенча мәгариф эшчәнлеге алып баручы учреждениеләрдә укый торган затларны бушлай туклану белән тәэмин итү.

агымдагы карарның 3 нче пунктының «б» һәм «г» а пунктчаларында күрсәтелгән затларга Минзәлә шәһәрендә җәмәгать транспортының гомуми кулланылышлы йөрү карталарын бирү.

2. 1 нче пунктта күрсәтелгән ярдәм чараларының түбәндәгеләргә күрсәтелүен билгеләргә:

а) махсус хәрби операциядә катнашучы (катнашкан) (бурычлар үтәүгә ярдәм итүче (ярдәм иткән) затларга;

б) Россия Федерациясе территориясенә кораллы басып керүне кире кайтару бурычларын үтәүче (үтәгән), Россия Федерациясе дәүләт чигендәге һәм махсус хәрби операция үткәрелә торган районнарга керүче Россия Федерациясе субъектлары территорияләрендә һәм Россия Федерациясенең дәүләт чикләрендә кораллы провокация барышында (алга таба - кораллы провокация) бурычларын үтәгән затларга;

в) Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы дәүләт хакимияте органнары карарлары буенча 2014 елның 11 маеннан алып Донецк Халык Республикасының һәм Луганск Халык Республикасының сугышчан

формированиеләре һәм органнарының, Донецк Халык Республикасының Кораллы Көчләре составында, Луганск Халык Республикасының Халык милициясе составында сугыш хәрәкәтләрендә (алга таба - сугыш хәрәкәтләре) катнашкан затларга;

г) әлеге пунктның «а» - «в» а пунктчаларында аталган затларның гаилә әгъзаларына, шул исәптән махсус хәрби операциядә катнашу белән (бурычлар үтәү белән) бәйле рәвештә һәлак булганнарга (вафат булганнарга), кораллы басып керүне кире кайтару бурычларын үтәү нәтиҗәсендә, кораллы провокация вакытында, сугыш хәрәкәтләре вакытында, хәбәрсез югалганнарга яисә махсус хәрби операциягә катнашу белән (күрсәтелгән бурычларны үтәү белән) бәйле рәвештә хәбәрсез югалган дип табылганнарга, шулай ук хәрби хезмәттән (хезмәттән, эштән) чыгарылганнан яки 1996 елның 31 маендагы «Оборона турында» N 61-ФЗ Федераль законында күрсәтелгән ирекле берләшмәләрдән чыгарылганнан соң үлгәннәргә, әгәр аларның үлүе махсус хәрби операциягә катнашу белән (күрсәтелгән бурычларны үтәү белән) бәйле рәвештә зыян килү (яралану, җәрәхәт алу) яки чирләү нәтиҗәсендә булса (алга таба - гаилә әгъзалары).

3. Агымдагы карарны гамәлгә ашыру максатларында гаилә әгъзалары дип таныла:

а) ире (хатыны);

б) 18 яшькә җитмәгән балалар, шул исәптән, әлеге карарның 2 нче пунктының «а» - «в» а пунктчаларында аталган затларның вафатыннан соң туган балалар, һәм аларга карата ата-ана булу хокукы 48 маддәнең 2 нче пунктына туры китереп билгеләнгән булса;

в) 18 яшькә җиткәнче инвалид булган 18 яшьтән өлкәнрәк балалар;

г) көндезге формада укыган мәгариф учреждениеләрендә белем ала торган 23 яшькә кадәр балалар;

д) әлеге карарның 2 нче пунктының «а» - «в» а пунктларында аталган затлар белән бергә яшәүче ата-аналар, яки аларның һәлак булу (үлү) көненә алар белән бергә яшәгән ата-аналар;

е) әлеге карарның 2 нче пунктының «а» - «в» а пунктчаларында аталган затларга тәэмин ителә торган затлар, яки аларның һәлак булу (үлү) көненә аларга тәэмин ителгән затлар.

4. Әлеге карарның 1 нче пунктында күрсәтелгән ярдәм чаралары агымдагы карарның 2 нче пунктында күрсәтелгән затларга махсус хәрби операция тәмамланган елдан соң киләсе ел ахырына кадәр кадәр күрсәтелергә, ә махсус хәрби операциядә катнашу, хәрби провокация барышында, хәрби бәрелештә катнашу (күрсәтелгән бурычларны үтәү)

нәтиҗәсендә имгәнү (яралану, җәрәхәт алу контузия алу) яки чирләү нәтиҗәсендә инвалид булучыларны инвалид дип танылган затларга билгеләнгән тәртиптә тану агымдагы карарның 2 нче пунктының «а» - «в» а пунктчаларында күрсәтелгән затларга, әлеге затларның гаилә әгъзаларына махсус хәрби операциядә катнашу (күрсәтелгән бурычларны үтәү) нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) затларга - сроксыз.

5. Агымдагы карарның 1 нче пунктында күрсәтелгән ярдәм чаралары агымдагы карарның 2 нче пунктының «а» - «в» а пунктчаларында күрсәтелгән затларга хәрби хезмәт үтәү (хезмәт үтәү) контрактларының датасына һәм урынына, 1996 елның 31 маендагы «Оборона турында» N 61-ФЗ Федераль законында күздә тотылган ирекле берләшмәләрдә булу контрактларына, Россия Федерациясе Оборона министрлыгы белән бәйләнгән килешүләргә (башка хокукый мөнәсәбәләрне раслаучы документларга), Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә йөкләнгән бурычларны үтәүгә ярдәм итүче оешмалар белән бәйләнгән контрактларга (башка хокукый мөнәсәбәтләрне раслаучы документларга) бәйсез рәвештә, түбәндәге документлар буенча күрсәтелергә тиеш:

федераль дәүләт органнары тарафыннан - агымдагы карарның 2 нче пунктының «а» һәм «б» а пунктчаларында күрсәтелгән затларга;

Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы башкарма хакимиятнең вәкаләтле органнары тарафыннан - агымдагы карарның 2 нче пунктының «в» а пунктчасында күрсәтелгән затларга.

6. Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Башкарма комитетының түбәндәге карарларының гамәлдән чыгарылуын танырга:

03.10.2022 №334 «Минзәлә муниципаль районы гражданнарының гаиләләренә, өлешчә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылганнарга ярдәм чаралары турында»;

21.11.2022 №385 «Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Башкарма комитетының 03.10.2022 №334 «Минзәлә муниципаль районы гражданнарының гаиләләренә, өлешчә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылганнарга ярдәм чаралары турында» карарына үзгәрешләр кертү турында»;

04.06.2024 №176 «Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Башкарма комитетының 03.10.2022 №334 «Минзәлә муниципаль районы гражданнарының гаиләләренә, өлешчә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылганнарга ярдәм чаралары турында» карарына үзгәрешләр кертү турында» карарына үзгәрешләр кертү турында»;

04.06.2024 №177 «Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Башкарма комитетының 03.10.2022 №334 «Минзәлә муниципаль районы

гражданнарының гаиләләренә, өлешчә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылганнарга ярдәм чаралары турында» карарына үзгәрешләр кертү турында».

7. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

8. Агымдагы карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасының Минзәлә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Бикеева Нэля Габдулловнага йөкләргә.

Җитәкче М.Р. Кәримов